| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

---

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>09.09.2025 ел | КАРАР<br>№ 171 |

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 14 августындагы 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 486-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Баулы шәһәр Советы *КАРАР ИТТЕ:*

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 14 августындагы 105 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 статьяның 1.1 пунктында «комплекслы үсеш турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә» сүзләрен «комплекслы үсеш максатларында» сүзләренә, «территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән» сүзләрен «комплекслы үсешкә тиешле» сүзләренә алмаштырырга»;

19 статьяның 5 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару территорияләре;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында bavly.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе                                        И.И. Гозәеров